Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

**2026 елның 26 маендэге** **№ 51**

**Кама Тамагы ш.т.п**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында «Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17.1 статьяларына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 26.02.2026 елның 26 февралендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2016 елның 18 апрелендәге 36 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 14 пунктындагы 2 пунктчасында «муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән» сүзләрен «коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4 бүлекнең 15 пунктындагы 10 пунктчасында түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә: «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Т.Гыйниятовка йөкләргә..

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы А. Н. Вазыйхов